УДК 82-94

***Н.И. Таиров, И.Н. Таиров***

# Г. ИСХАКЫЙ МӘСКӘҮДӘ МӨСЕЛМАН СТУДЕНТЛАР БЕЛӘН: БЕР ФОТОРӘСЕМ ТАРИХЫ

В статье, опираясь на материалы архивов, периодических изданий, воспоминаний, рассматриваются вопросы времени, места и истории появления фотоснимка Г. Исхаки со студентами в Москве, его расшифровки.

**Ключевые слова:** татары, предприниматели, студенты, фотоснимок, Г. Исхаки, Г. Тукай, Москва.

Гаяз Исхакыйның Мәскәүдә мөселман студентлар белән төшкән фоторәсеме 1995 елда безнең тарафтан татар эшмәкәренең гаилә архивыннан табылып, мәртәбәле «Сөембикә» журналының 6 нчы санда басылып чыкты [Таиров, 1995, с. 14]. Алга таба әлеге фотодокумент белән галим-тикшеренүчеләр дә кызыксынып, ул Г. Исхакый әсәрләре җыентыгының 3 нче томында дөнья күрде. 2002 елда әлеге фотоны без «Акчуриннар» китабына да урнаштырдык [Таиров, 2002, с. 30, 96–97]. Соңгы елларда бу фотоны өйрәнү эшен дәвам итеп, Акчурин, Камалов, Рәхимов, Терегулов нәселеннән булган кайбер шәкертләрнең шәхесен ачыклауга ирештек.

Эзләнү, өйрәнү барышында рәсемнең кайбер мәгълүматлар язылган икенче бер экземпляры да табылды. Мәсәлән, бу нөсхәдә фотога төшү датасы һәм андагы кешеләрнең исемлеге дә китерелә. Әлеге кыйммәтле тарихи чыганакка инде 100 елдан артык, шуңа күрә аның сакланышына бераз зыян да килгән. Бу, нигездә, андагы язуларга карый. Рәсемнең аскы өлешенә сурәттәге кызлар һәм егетләрнең, Г. Исхакыйның исемнәре язылган булган. Кызганычка каршы, әйтеп үтелгәнчә, аларның сакланышы бик түбән дәрәҗәдә. Текстның аерым урыннары кыршылып, бөтенләй юкка чыккан, кайбер җирләре бик нык бозылган. Шулай да күренекле галим, филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗанов аларның кайберләрен ачыклау мөмкинлегенә ирешә алды. Мәскәү студентларының Г. Исхакый белән берлектәге күмәк фотода түбәндәге исемнәр язылган:

1. Хәлил Галиев, Бари Госманов, Гали Рәхимов, Сәгыйть Дебердиев, Ибраһим Аитов, Гомәр Акчурин, Мостафа Шәкулов, Гомәр Терегулов, Сөләйман Агишев, Мөхәммәт Терегулов, Мостафа Сәйфелмөлеков, Таһир Исаев, Гайнетдин Дебердиев;

2. Гариф Кәримов, Мәрьям Айдарова, Ак кәгазь Рустамова (Дустанова – ?), Рабига Богданова, Гаяз Исхаков, Мәрьям Паташова, Хәтимә Камалова, Зөһрә Акчурина;

3. Гыйззетдин Сәйфелмөлеков, Шәйхулла Алкин, Нурмөхәммәт Татабаев.

Фотографиянең арткы ягына фотоательеның адресы язылган: «Фотогр. М. Перцев. Москва, Пятницкая 17». Шунда ук кемдер каләм белән фотога төшү вакытын һәм урынын да теркәгән: «8-го апреля 1914 г. Москва». Әлеге уникаль тарихи документның алгы ягында ательеның башка шрифтта бирелгән исеме дә сакланган.

Фото безгә моннан бер гасыр элек Мәскәүнең генә түгел, ә XX йөз башында Россиядәге татар студентларының кыяфәтләрен, килеш-килбәтләрен күзалларга ярдәм итә. Бу тарихи фотода, бер тамчы суда диңгезне күзаллагандай, 1917 елга кадәр илнең татар бергәлеге, төгәлрәге – аның студентлары гәүдәләнә. Авылларда һәм зур булмаган шәһәрләрдә туып үскән студентлар Россиянең ерак төбәкләрендәге чынбарлыкны яхшы беләләр. Мәскәүгә укырга килгән яшьләр, белем алып, илгә һәм үз халкына хезмәт итү максаты белән яши. Шунысы игътибарга лаек, аларны авырлыклар да, матди кыенлык та, туган якларыннан еракта булу да куркытмый. Илдәге татар бергәлегенең белемле өлеше, ягъни губерна үзәкләрендәге һөнәри уку йортларын тәмамлап килгән яшьләр Мәскәү студентлары арасында үз урыннарын тиз табалар, кушылып китә алалар. Алар, барыннан да бигрәк, эшмәкәрлек (җитештерү, сәүдә һәм финанс) өлкәсен киңрәк үзләштерергә омтылалар.

Безнең каршыбыздагы фотода Г. Исхакый янәшәсендәге студентлар – Россия татар сәүдәгәрләренең, сәнәгатьчеләренең, дин әһелләренең һәм мәгърифәтчеләрнең балалары. Укучыларның географияләре дә шактый киң: Сембердән, Саратов, Казан, Оренбург, Уфа губернасыннан. Алар арасында Акчурин, Дебердиев, Аитов, Рәхимов, Терегулов кебек күренекле татар эшмәкәрләренең нәсел дәвамчылары бар.

Гомәр Акчурин, мәсәлән, күренекле татар фабриканты һәм меценаты Хәсән Акчуринның улы. Мостафа Сәитшәкулов – Тимербулат Курамша кызы Хәнифәнең улы. Акчуриннарның нәсел шәҗәрәсендә аларны Тимай-бай Акчуриннарның оныклары дип карарга мөмкин. Тимай байны бер шигырендә Габдулла Тукай да телгә ала [Тукай, II т., б. 221, 359–360].

Зөһрә Акчурина – Исмәгыйль Курамша улы Акчуринның кызы. Ул, Сембердәге кызлар гимназиясен тәмамлап, Мәскәү югары уку йортларының берсендә белем ала. Җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша. 1917 елның 24–27 нче апрелендә Казанда узган Бөтенроссия мөселман хатын-кызлары корылтаенда вәкил буларак катнаша.

Тагын бер студент – Гайнетдин Дебердиев турында аерым тукталып үтик. Ул – Саратов губернасы Кузнецк өязендәге атаклы постау фабрикасы хуҗалары һәм сәүдәгәрләр нәселе вәкиле. Гайнетдин күпмедер дәрәҗәдә Акчуриннар белән дә бәйләнешле була. Акчуриннар белән Дебердиевлар үзара бик тыгыз

элемтәдә булалар, алар арасында гаилә-туганлык мөнәсәбәтләре урнашу да билгеле. Гайнетдин үзе Йосыф бай Акчурин (Иске Тимошкино авылындагы постау фабрикасы хуҗасы) хатынының кардәше була. Гайнетдин Дебердиев студентлык чорында Акчуриннар нәселеннән булган яшьтәшләре белән даими элемтәдә яши. Болганчык 1917–1918 елларда Гайнетдин, күңеленә тынычлык эзләп, Иске Тимошкиногa (Зиябашы) – Акчуриннарга кунакка килә. Бу авылда аны белүчеләр күп булмый. Ләкин шушы төбәктәге 1917–1918 елның канлы вакыйгасы нәкъ менә аның исеме белән бәйле. Йосыф Акчуриннарга еш кына кызылармиячеләр килеп, алтын һәм башка кыйммәтле әйберләр эзлиләр, аларны фабриканттан таләп итәләр. Беркөнне шундый эзләнүләр вакытында Гайнетдин балконга чыккан була һәм атып үтерелә. Аны авыл зиратына – Акчуриннар нәселе янәшәсенә җирлиләр. Авыл халкы, егетне якыннан белмәсә дә, аның үтерелүен бик авыр кабул итә. Хәтта бу вакыйгага бәйле бәет чыгаралар. Халык телендә йөргән әлеге бәетнең бер өлешен Ульяновск өлкәсе Барыш районының Калны (Калды) авылында яшәүче Зөләйха Әбдерәшит кызы Таировадан (1916–2001) язып алган идек.

Бәеттә кызылгвардиячеләр отряды җитәкчесе Шамил турында да сүз бар. Авыл өлкәннәре бу исемне күренекле татар язучысы һәм сәяси эшлекле Шамил Усманов белән бәйлиләр. «Канлы көннәрдә», «Беренче адым» пьесалары, «Легион юлы» повесте һәм башка әсәрләр авторы нәкъ менә Сембер губернасында яңа хакимият оештыруда катнашкан.

Фотода Акчуриннарга турыдан-туры мөнәсәбәте булган затлардан Сөләйман Агишев та бар. Ул фабрикантларның якын кешесе була. Акчуриннар, тәрбия һәм белем бирүне үз өсләренә алып, егеткә башта Сембер сәүдә көллиятендә, аннан Мәскәүдә дәрәҗәле генә югары уку йортында белем алырга мөмкинлек тудыралар. Туганнары архивында аның уку йортын уңышлы тәмамлавы турында документ та саклана. 1917 елга кадәр ул Акчуриннар ширкәтенең берсе белән идарә итә. Кызганычка каршы, ул революцион күтәрелеш чорында юкка чыга. Шул төбәктә яшәүче аксакалларның мәгълүматларына караганда, ул фабрикалар бистәсеннән Акчуриннар белән бергә киткән булырга тиеш.

Фотодагы студентлар арасында постау фабрикасы хуҗасы, сәүдәгәр, хәйрияче һәм меценат Дебердиевлар нәселе вәкиле дә бар – ул Сәгыйть Дебердиев. Сәйфелмөлековлар исә икесе дә Оренбург ягы татар эшмәкәрләренә барып тоташалар. Рәсемдә галим, язучы булып танылган Гали Рәхимов та (Гали Рәхим) Казанның татар сәүдәгәрләре нәселеннән. Үз вакытында ул да Казан сәүдә көллиятен тәмамлап, Мәскәү коммерция институтына укырга керә.

Фотода татар студент кызлары төркеме булу игътибарны аеруча җәлеп итә. Алар Мәскәүнең төрле югары уку йортларында укыганнар. Хәтимә Камалова –

танылган дин эшлеклесе, Чистай мәчете имамы Мөхәммәдзакир Камаловның кызы. Хәтимә, Мәскәүдә белем алып, үз гомерен иң авыр, әмма игелекле һөнәр – медицинага багышларга җыена. Кама буенда үскән кызның ниятләре изгедән булса да, кызганычка каршы, ул тормышка ашмый кала. Совет хакимиятенең беренче елларында ук ул вафат була.

Язучы Г. Исхакый белән янәшә үк утырган Мәрьям Поташова Балкан сугышы вакытында, бер төркем татар кызлары (Гөлсем Камалова, Мәрьям Якупова, Рокыя Юнысова) белән Төркиядә була. Анда кызлар үзләрен татар һәм төрек дөньясында таныталар. Мәрьям Гөлсем Камалова белән яхшы таныш була. Гөлсем исә, 1913 елда фабрикант Габдулла Акчуринга кияүгә чыгып, Сембер губернасындагы Гурьевка авылында яши. Мәрьям 1916 елда аларда кунакта була һәм аларның шул чакта бергәләп төшкән фотолары да саклануы хакында Гөлсем Камалованың (Акчуринаның) кызы искә алды. Күмәк фотода татар кызларының булуы Россия җәмгыятендә аларның роле арта баруны дәлилли.

Г. Исхакый белән очрашу, аның белән фотога төшү кайбер яшьләр өчен, бәлки, беренче очрашу һәм якыннан танышу да булгандыр. Мөгаен, алар бу очрашуны күңелләрендә гомер буена саклаганнардыр.

Кайбер студентлар, язучы белән танышып, аралашып яшәү белән беррәттән, Г. Исхакый нәшер иткән татар телендәге газеталар белән хезмәттәшлек тә итәләр. Шәйхулла Алкин Казанның милли зыялылары вәкиле була, югары белемле коммерсант, балалар язучысы. Мәскәүнең коммерция институтында укыган елларында ул «Ил» газетасында һәм «Ак юл» журналы битләрендә мәкаләләре һәм хикәяләре белән катнаша. Шул ук вакытта Ш. Алкин яшьләр кичәләре оештыруда да актив катнаша [Исхаков, б. 292, 396].

Бу кызыклы фото, мөгаен, Г. Тукай исеме белән бәйле булгандыр дигән фикер туа. Нәкъ менә 1914 елның апрель көннәрендә илнең татар зыялылары һәм шигърияткә омтылучылар Г. Тукайның вакытсыз вафат булуына бер ел тулуны билгеләп үтәләр.

Ул көннәрдә Г. Тукай истәлегенә багышланган чаралар Россиянең татарлар яшәгән төбәкләрендәге уку йортларында һәм эш урыннарында уздырыла. Фотоның максаты да шул вакыйгаларның берсен мәңгеләштерү ниятеннән булса кирәк. Әлеге төркем вәкилләре дә Г. Тукай һәм башка татар язучылары белән очрашуларда аларның иҗаты турында сөйләгәннәрдер, шигырьләрен укыганнардыр. Шундыйларның берсе дип фабрикант һәм меценат Хәсән Акчуринның улы Гомәр Акчуринны әйтергә мөмкиндер, чөнки танылган шагыйребез 1909 елда Акчуриннарда (Сембердә) була. Ул анда Акчуриннар гаиләсендәге балалар, яшүсмерләр белән аралашмый калмагандыр. Шагыйрьнең Акчуриннарда булу фактына татар язучылары һәм драматурглар, театр коллективлары әле хәзер дә зур игътибар бирәләр.

Шуны әйтергә кирәк, XIX–XX гасырлар чигендә татар сәүдәгәрләре һәм сәнәгатьчеләре балаларын милли әдипләребез, җырчыларыбыз, музыкантлар, театр коллективлары белән таныштыруны үз бурычлары дип санаганнар. Моңа 1912 елда Г. Тукайның С.-Петербургта булуын мисал итеп китерергә була. Мәсәлән, эре сәүдәгәр, җәмәгать эшлеклесе, меценат Галим Максутов шагыйрь белән очрашуга улы Кәримне дә алып килә [Таиров, с. 120–122]. Г. Тукай белән таныш булган студентлардан Гали Рәхимне дә әйтми калдыру мөмкин түгел.

Мәскәүдә һәм С.-Петербургта уздырылган төрле очрашуларга чакырулы кунаклар арасында һәрчак татар язучылары, журналистлары һәм артистлары да булган. Алар хакындагы мәгълүматлар татар вакытлы матбугаты битләренә теркәлгән. Андый чаралар ике башкалада укучы яки яшәүче татар яшьләренең очрашып аралашу, фикер алышу урыны саналган. Яшьләр шулай ук Россия мөселманнарының дини һәм дөньяви бәйрәмнәрен билгеләп үтәләр.

Фотодагы башка затларның язмышы да төрле юнәлеш буенча китә. Аларга әле күз алдына китерә алмастай җитди сынаулар кичерергә туры килә. Алар тормышында, эшчәнлегендә 1917 ел һәм аннан соңгы еллар вакыйгалары зур роль уйный. Кызганычка каршы, Октябрь инкыйлабы аларның яшәү рәвешен тискәре якка үзгәртә, хәтта фаҗигагә әйләндерә. Күбесе, хәтта, укуларын да тәмамлый алмый калалар. Белем алып өлгергәннәренең кайберләренә һөнәрләре буенча ихтыяҗ булмый – эш таба алмый интегәләр. Андыйлар үз илләрендә кирәксез кешегә әйләнә.

Яңа хакимият аларга шикләнеп карый, яки турыдан-туры дошманы итеп күрә, күп гамәлләрен большевиклар корткычлык дип саный. Яңа җәмгыятьне алар үзләре дә кабул итә алмый. Өстәвенә, кайберләре нигезсез кимсетелүләргә һәм, хәтта, репрессияләргә дучар ителә.

Фотодагы студентларның кайберләре 1917–1918 елгы вакыйгалардан соң Россиядән китәргә, калган гомерләрен чит җирләрдә уздырырга мәҗбүр була.

Фоторәсемне игътибар белән өйрәнү кайбер нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Фотосурәт – кыйммәтле чыганак булып хезмәт итә. Андагы затларның һәркайсын тәфсилләп өйрәнү яшәүнең мәгънәсе һәм шул чор татар язучыларының инде танылып өлгергән вәкиле Г. Исхакый иҗаты хакындагы фикерләребезне тирәнәйтә. Г. Исхакыйның гаять бай әдәби иҗаты, әле XXI гасырда да, татарларның гына түгел, Россия Федерациясендәге һәм чит илләрдәге башка халыкларның да игътибарын җәлеп итә. Мәгълүм булганча, язучының тормыш юлы вакыйгаларга гаять бай, шул исәптән сәфәрләр һәм күченеп йөрүләр дә күп булган. Фоторәсем аша без Г. Исхакыйның гына түгел, андагы студентларның да шул вакытта кайда булуын, төгәл көнен билгели алабыз (бу хакта фотода күрсәтелгән). Бер үк вакытта тарихи

әһәмияткә ия фотодокументта студентлар исемлеге дә бирелгән. Әнә шулай, акрынлык белән булса да, язучы биографиясендәге һәм шушы төркем вәкилләренә кагылышлы «ак тапларны» киметә барабыз. Гомумән алганда, әлеге мәкалә Г. Исхакыйның күпкырлы иҗатын һәм татар студентларының биографияләрен алга таба тикшерүгә ярдәм итәр, дигән өметтә калабыз.

**Әдәбият**

*Таиров Н.* Фотография Гаяза Исхаки // Сююмбике. 1995. № 6. Б. 14.

*Таиров Н.И.* Акчурины. Казань. 2002. С. 30, 96-97.

*Тукай Г.* Әсәрләр: 6 томда: академик басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011; 2 т.: шигъри әсәрләр (1909–1913). 2011. Б. 221, 359–360.

*Исхаков М.Г.* Әсәрләр: 15 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. 2 т. Б. 292, 396.

*Таиров Н.И.* Г. Тукай и Максутовы // Материалы международной научно-практической конференции, посвященной 125-летию со дня рождения Г. Тукая «Наследие Г. Тукай в контексте национальных культур» (25 апреля 2011 г.). Казань, 2011. С. 120–122.

***Таиров Наил Измаил улы,***
*тарих фәннәре докторы, Казан дәүләт мәдәният институты профессоры*

***Таиров Илһам Наил улы,***
*Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Профессор А.Ф. Агафонов исемендәге Республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсе табибы*